Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы
10 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар

Максималь балл – **45**

1. Әдәбияттагы нинди юнәлеш турында сүз баруын языгыз (2 балл):

- аның асылын Урта гасыр мөселман дөньясында киң таралган тәгълимат тәшкил итә;
- аның тарафдарларын башка төрле итеп «диндар», «дәрвиш», «тәкъва», «акыл иясе» дип йөрткәннәр;
- әдәбияттагы әлеге күренеш мөселман кешесенең үз-үзен, рухын камилләштерү юлы белән Аллага якынаюын һәм кушылуын күздә тоткан төрле системадагы дини-фәлсәфи, мистик карашлар һәм йолалар җыелмасыннан гыйбарәт.

Җавап: суфичылык әдәбияты

2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):

а) мәрсия, мәдхия, бәет, газәл

ә) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар

б) сюжетлы шигырь, поэма, баллада, нәсер

Җавап: а) мәрсия, мәдхия, бәет, газәл

3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.

а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):

1) 2) 3)





а) ә) б)

_____

Җавап: 1) ә; 2) б; 3) а.

ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):

_____

_____

_____

Җавап:

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»

Габдрахман Әпсәләмов «Ак чәчәкләр»

Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять»

ә) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).

_____

_____

_____

_____

_____

_____

4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):

1) Мансур	а) «Әйтелмәгән васыять»
2) Суфиян	ә) «Галиябану»
3) Исмәгыйль	б) «Кыйссаи Йосыф»
4) Йагъкуб	в) «Ак чәчәкләр»

Җавап: 1) в; 2) а); 3) ә; 4) б.

5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.

... Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә (исенә төшерә) ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

а) Әсәрнең исеме (1 балл)_____

ә) Әсәрнең авторы (1 балл)_____

б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә нәрсә күренеше бирелә? (3 балл)_____

_____

_____

в) Ана теләгенең көчен шигырьдә кайсы детальләр белдерә, шуларны язып чыгыгыз (3 балл)_____

_____

_____

_____

_____

_____

г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләп языгыз (3 балл) _____

_____

_____

_____

Җаваплар:

а) Ана догасы

ә) Габдулла Тукай

б) Шигырьнең беренче өлешендә төнге авыл күренеше бирелә.

в) Догага күтәрелгән куллар, улына Ходайдан бәхет сорау, тамчы-тамчы күз яшьләре.

г) Барлык аналар үз балаларына яхшылык, балаларының бәхетле булуын тели.

6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).

Кәләш, кияү, йола, туй, никах, мәҗлес, ак бөркәнчек, бал-май, хөрмәт итү, мәхәббәт хисе, бәхет теләү, әти-әни, туганнар.

Иншгызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.

Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.

Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.

.